

Галимнәр сәләтсез балалар юк, һәркемнен нәрсәгә дә булса сәләте, омтылышы була диләр.
Баланын һәвәслелеген, талантын торлечә билгеләп була. Тиешле шартларда яшәгән ба-лаларнын 2-9 проценты бик сәләтле була. Интеллектлылыгы яшьләренә туры килгән балалар 50 процент тәшкил итә. Алар доньяны танып белvдә һәм һонәри осталыкта гаять зур унышларга ирешергә, мәктәптә белем алу елларында бик сәләтле балаларга тигезләнергә момкин. Без шундый сәләтле бер бала турында сvз алып барачакбыз. Ул Ләмберә районы Татар Тавла топ мәктәбенен 2 сыйныф укучысы Аида Байгельдина. Аида мәктәптә «5» билгеләренә генә укырга тырыша. Сыйныф житәкчесе Гельсирә Няим кызы Туктарова Аида турында болай ди: «Аидабыз һәрбер эштә актив, булдыклы, ижади укучыларнын берсе. Телләр ойрәнергә ярата. Ана соте белән кергән татар телен ярата. Альфия Фатих кызы Муртазина бу олкәдә ныклы белем генә биреп калмый, мәдәниятыбыз белән таныштыра, укучыларнын сәләтләрен торле яклап vстерә. Укучылары белән татар курчак театрын куя. Аида татар курчак театрында да катнаша». Ә әнисе Рима Фатих кызы тагы ул чигv чигәргә, телләр ойрәнергә ярата, ди. Инглиз телен vзләштерә, Ислам мәдәни Үзәгенә барып, Динара Шабаева укыткан гарәп теле дәресләре белән таныштык: киләчәктә Аида бу телне дә ойрәнергә исәбе бар, ди әнисе. Язганыма дәлил буларак, тагы бер мисал. Мордовиябезнен торле почмак-ларында «Туган тел» бәйрәмнәре vтә. Татар Тавла мәктәбендә «Туган тел» конен әле генә билгеләп vткәннәр. Толерантлылык хисен тәрбияләv йозеннән, бу чарада Мордовия Республикасында ватандашларыбыз мордвалар очен туган телләре булган мукшы, әрзә телләре турында да сvз барган. Респуб-ликабыздагы татарлар гомер-гомергә рус, мокша, эрзя һәм башка милләтләр белән тыгыз аралаша, дус яши. Без һәр халыкнын мәдәниятен кадерлибез. Шуна Аида Байгельдина әрзә телендә ин танылган жырнын берсен - «Луганяса келунясь» ны бии-бии башкара. «Пандо прясо» дигәнен дә жырлый ул, тик бу чарада аны башкармый кала. Ә 16 апрельдә, Ботенроссия мордва телләре коне кысаларында vткән «Туган телем, мин сине саклыйм!» флешмобында, бу ике жырны да башкара. Сез бу язганнарны укыгач, ә татарча жырлыймы сон бу бала, туган телендә,

дип сорарсыз. Жавапка бер мисал: vткән ел узган «Сабантуй» бәйрәмебездә олы сәхнәдән ана бик тә килешеп торган милли киемнәребезне киенеп татарча рәхәтләнеп жырлады ул. Әйтеп китәргә кирәк, Аида Байгельдина Саранск шәһәре №6 музыкаль мәктәбенен фортепьяно классына оченче ел йори. Тагы ул 2021 елдан алып «Умарина» хокvмәт жыр һәм бию ансамблендәге «Яблонька» балалар вокал студиясендә шогыльләнә; унышлы чыгышлар ясый.
Хәзерге заманда балаларнын кече яшьтән vк ни дәрәжәдә сәләтле, талантлы булуларын укытучылар, психолог, социаль педагоглар ойрәнергә hәм алардагы бу сыйфатларны vстерергә ярдәм итә. Талантлы бала һәрвакыт vзенен жәмгыятькә кирәклеген тоеп, алга таба зур эшләр башкара алуына ышанып яшәргә тиеш. Аида Байгельдина шунын бер мисалы.

**Наилә НАСЫРОВА**